СОВЕТ МЕМДЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422728, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Мемдель, ул. Кооперативная, 30

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘМДӘЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422728, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мәмдәл авылы, Кооператив ур, 30

Тел./факс: +7(84365) 60-2-37, e-mail:Memdel.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**14 ноябрь 2024 ел** **№ 100**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 октябрендәге “Физик затлар милкенә салым турында”гы 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, «салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Мәмдәл авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 24.11.2015 ел, №9 карарына (30.04.2018 ел, № 92, 24.08.2018 ел, № 102, 25.12.2018 ел, №123, 28.11.2022 ел, №54, 14.09.2023 № 70, 13.11.2023 №74 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2,5 процентка карата: һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;»

1.2. 2 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025-2027 елларда 1,2 процент, 2028 елдан 2%:

Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары; Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата.»

2. Әлеге карар законлы көченә 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма ул рәсми рәвештә игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач керә.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru

Мәмдәл авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сафиуллин